ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ УРЫССУ БИСТӘСЕ СОВЕТЫ

(V чакырылыш)

**V чакырылышның чираттан тыш утырышы**
**КАРАРЫ**

**№ 5 Урыссу штб 24.03.2026 ел**

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы бистәсе Советының 23.04.2025 №6 карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы бистәсендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

"Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ санлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»гы 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ санлы Федераль закон, «Коррупциягә каршы көрәш турында»гы 25.12.2008 № 273-ФЗ Федераль законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы законы, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 25.06.2013 № 50-ТРЗ карары нигезендә, "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы бистәсе" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, 2026 елның 18 февралендәге 02-08-01 номерлы протест нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы бистәсе Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы бистәсе Советының 23.04.2025 №6 карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы бистәсендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Нигезләмәнең 3.9 статьясының 3.9.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.9.1. Муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы граждан, муниципаль хезмәткәр әлеге Федераль законда билгеләнгән очракларда яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында "Коррупциягә каршы тору турында" гы 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ санлы Федераль законда каралган белешмәләрне тапшыралар. Күрсәтелгән белешмәләр Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ санлы Федераль законда каралган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру өчен билгеләнгән тәртиптә, срокларда һәм форма буенча тапшырыла.»

1.2. Нигезләмәнең 3.9 статьясының 3.9.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.9.2. Тиешле исемлеккә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче муниципаль хезмәткәр "Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында" 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ санлы Федераль законда каралган чыгымнар турында белешмәләрне Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан мондый белешмәләрне тапшыру өчен билгеләнгән тәртиптә һәм формада тапшырырга тиеш.»;

1.3. Нигезләмәнең 3.9 статьясының 3.9.7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.9.7. Муниципаль хезмәткәрләргә «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25

декабрендәге 273-ФЗ санлы Федераль законда каралган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне һәм 2012 елның 3 декабрендәге "Дәүләт Вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында"гы 230-ФЗ санлы Федераль законда каралган чыгымнар турында белешмәләрне тапшырмау, әгәр мондый белешмәләрне тапшыру мәҗбүри булса йә белә торып тулы булмаган белешмәләр тапшыру муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итүгә китерә торган хокук бозу булса, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш;

1.4. Нигезләмәнең 3.9 статьясының 3.9.11 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.9.11. Контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар әлеге статьяның 3.9.1 пунктында күрсәтелгән белешмәләрне Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Башлыгына (Рәисенә) тапшыралар, мондый вазыйфаны биләүче зат әлеге статьяның 3.9.1 һәм 3.9.2 пунктларында күрсәтелгән белешмәләрне тапшыралар.;

1.5. Нигезләмәнең 4.1 статьясының 4.1.3 пунктының 10 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Коррупциягә каршы көрәш турында»гы 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ санлы Федераль законда каралган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru; 17.12.2013 елны Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан ЭЛ № ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык бирелгән) бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштыру юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми халыкка игълан ителгән вакыттан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы Ютазы
муниципаль районының "Урыссу
шәһәр тибындагы бистәсе" муниципаль
берәмлеге Советы Рәисе,
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районының
шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе
Башлыгы А.Ә. Шәфигуллин